**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**05.09.2022 ел** **№ 878**

**Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы муниципаль максатчан программаны, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 02 июнендәге 556 номерлы карарын, Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарын, «Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына Комиссия составын раслау хакында» Башкарма комитетның 2022 елның 13 июлендәге 695 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк

савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- субсидия алучы - физик зат – алты һәм аннан күбрәк савым сыерына ия булган граждан (алга таба - Алучылар);

- граждан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә теркәлгән;

- субсидия сорап мөрәҗәгать иткән вакытка гражданның шәхси хуҗалыгында тиешле авыл җирлегенең хуҗалык кенәгәсендә теркәлгән алты һәм аннан да күбрәк сыер бар.

- субсидия алучының салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнмәгән бурычлары булмаска тиеш».

1.2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктларында күрсәтелгән документлар кергәндә һәм 2.1 һәм 2.2 пунктлары таләпләренә туры килгәндә, Башкарма комитет:

- гаризаны журналда терки һәм документларны карау өчен муниципаль берәмлек бюджетыннан Субсидияләр бирү комиссиясенә җибәрә.»

1.3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризаны теркәгәннән соң 30 эш көне эчендә Комиссия бирелгән документларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүгә тикшерә һәм документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында яки аларның туры килмәве турында карар кабул итә.»

1.4. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет Комиссия карарын алганнан соң 30 эш көне дәвамында оешманың гаризасын кире кагу турында, яисә субсидия бирү турында карар кабул итә һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»

1.5. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидия күләме факттагы тотылган чыгымнарны тәшкил итә, әмма бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка 30 000 (утыз мең) сумнан артык түгел.

1.6. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.11. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү Башкарма комитет һәм субсидия алучы арасындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү типовой формага (3 нче кушымта) туры китереп, субсидия бирү турында Карар нигезендә төзелә.

Килешүдә карала:

- субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;
- аны күчерү тәртибе һәм сроклары;
- аларны каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре;
- бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүчегә әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган элек җиткерелгән лимитлары кимү очрагында, килешүнең яңа шартларын килештерү шартлары яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешмәгәндә килешүне өзү;
- субсидия алучының Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроль органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалыгы.»

1.7. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 2.12. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Башкарма комитет субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә субсидия алучыга ачылган исәпләү яисә корреспондент счетына әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән документларны Тәртипнең 2.6 пунктында билгеләнгән срокларда карау нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет (бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче) тарафыннан субсидия бирү турында күрсәтмә кабул иткән көннән соң килүче 14 эш көненнән дә соңга калмыйча күчерә.

1.8. «Финанс ярдәме алуга заявка» 1 нче кушымтаны, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.9. «Финанс ярдәменең белешмә-расчеты» 1 нче кушымтасын, әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.10. «_____ номерлы Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында килешү» 3 нче кушымтаны, әлеге

карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.11. «Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр алуга алты һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнар РЕЕСТРЫ» 4 нче кушымтасының яңа формасын расларга.

2. Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 13 июлендәге 695 номерлы карарын исәпкә алып), «Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына Комиссия составын раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә һәм комиссиянең түбәндәге әгъзаларын килешү буенча билгеләргә:

2.1. Биектау муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы - Кәримов Рәхимҗан Зариф улын;

2.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе - Вәлиуллина Рамилә Шамил кызын;

2.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы - Таҗиев Илдар Илгизәр улын.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Д.Ф.Шәйдуллин

1 нче кушымта

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» карарына

Финанс ярдәме алуга гариза

Мин ____________________________________________________________

(шәхси ярдәмче хуҗалык иясенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча яшим: ______________________________________________

(яшәү урыны адресы)

Финанс ярдәме алуга программада катнашучылар составына кертүегезне сорыйм.

Катнашучы турында белешмәләр:
1.Паспорт белешмәләре:
серия_________№____________________________________________
Кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән:
____________________________________________________________
ИНН ____________________________________________

Мөрәҗәгать итү датасына сыерлар саны_____________________________ баш

2.Контакт телефоны, E-mail _________________________

Гариза бирү датасы «___» _______, 202__ел .
Шәхси ярдәмче хуҗалык
иясенең имзасы
_____________/__________________________________________/

2 нче кушымта
«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» карарына

Финанс ярдәме белешмә-расчеты

| | |
|---|---|
| ШЯХ Ф.И.А. тулысынча | |
| 2022 елның 01 июненә сыерлар саны | |
| Гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплау, сум. | |
| ШЯХ хуҗасына тиешле матди ярдәмнең гомуми күләме, сум. | |

Дата
Авыл җирлеге башлыгы (Ф.И.А., имза, мөһер)

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (Ф.И.А., имза, мөһер)

3 нче кушымта
«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» карарына

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында**

**КИЛЕШҮ**

**№ _____________**

Биектау т.юл.стан. пос. "_____" _____________, 2022 ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, аңа, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле бюджеты акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе Бюджет кодексының **78 статьясы** нигезендә субсидия бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән, алга таба Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты дип аталучы, Нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкчесе ______________________________________________ йөзендә, бер яктан, һәм ______________________________________________________________________________, алга таба "Алучы"дип аталучы, икенче яктан, алга таба "Яклар" дип аталачак, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 20___елның «____» _______ ______ номерлы карары нигезендә (алга таба - Субсидия бирү кагыйдәләре) һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 20___елның «____» _______ ______ номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә әлеге Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр.

## I. Килешүнең предметы

1.1. Әлеге килешүнең предметы булып 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле бюджетыннан субсидияләр бирү тора:

1.1.1. шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкта алты һәм аннан күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты алуга бәйле Алучы чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында.

## II. Субсидия бирүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Субсидия Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле бюджеты акчаларын алучы буларак, әлеге Килешүнең **I бүлегендә** күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә түбәндәге күләмдә бирелә: БК коды буенча_____________________________ -________________________ (сумма сүзләр белән) сум.

## III. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидия субсидияләр бирү Кагыйдәләре нигезендә бирелә:

3.1.1. әлеге Килешүнең **I бүлегендә** күрсәтелгән максатларга:

3.1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Алучы тарафыннан, аларны каплауга Субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге Килешү нигезендә Субсидия бирелә торган шәхси ярдәмче хуҗалыкта сыер саву аппараты алу фактын раслаучы документларны Алучы тапшырганда;

3.2. Субсидия башка шартларны үтәгәндә бирелә, шул исәптән:

3.2.1. Субсидия бирү датасына субсидия алучыда булган баш санына субсидия бирү елының 31 декабренә торышы буенча сыерларның баш санын саклап калуны тәэмин итү турында.

3.2.2. Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетыны 20___елның «____» _______ ______ номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары белән билгеләнгән форма (4 нче кушымта) буенча субсидия Алучы субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр 3.2.1 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләр күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирә.

3.2.3. Асылда җитештерелгән чыгымнарны раслаучы документлар булып товар накладное (товар чегы) һәм касса чегы (керү-касса ордеры), саву аппараты паспорты күчермәсе тора.

3.3. Субсидияне күчерү Алучы хисабына банкта ачылган «____________________» бүлегенең №_____________________ р/с _____________________________, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетында әлеге Килешүгә кул куелган көннән соң килүче 14 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

## IV. Якларның үзара хезмәттәшлеге

4.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

йөкләмә ала:

4.1.1. әлеге Килешүнең **III бүлеге** нигезендә Субсидия бирүне тәэмин итәргә:

4.1.2. Алучы тарафыннан тапшырыла торган документларны, шул исәптән Субсидия бирү кагыйдәләренә туры килү-килмәүне, аларны Алучыдан алган көннән алып 30 эш көне эчендә тикшерүне гамәлгә ашырырга;

4.1.3. әлеге Килешүнең **3.3 пункты** нигезендә күрсәтелгән Алучының счетына Субсидия күчерүне тәэмин итәргә;

4.1.4. Субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын Алучының, шул исәптән, әлеге Килешү нигезендә Алучы тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген, планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән, үтәүне түбәндәгеләр нигезендә контрольдә тоту:

4.1.5. әлеге Килешүнең **4.3.4 пункты** нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты соратуы буенча Алучы тарафыннан тапшырылган документлар;

4.1.6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән яисә җирле үзидарә органыннан, дәүләт финанс контроле органыннан, Алучы тарафыннан Субсидия бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә каралган тәртипне, максатларны һәм шартларны бозу факт(лар)ы турында мәгълүмат алынган очракта, шул исәптән әлеге Килешү нигезендә Алучы тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелгәндә, Алучыга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле бюджетына субсидияне күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда кире кайтаруны тәэмин итү турындагы таләпне җибәрергә;

4.1.7. Алучы җибәргән тәкъдимнәрне, документларны һәм башка мәгълүматны, шул исәптән әлеге Килешүнең **4.4.1 пункты** нигезендә, аларны алган көннән соң 30 эш көне эчендә карарга һәм кабул ителгән карар турында (кирәк булганда) Алучыга хәбәр итәргә;

4.1.8. әлеге Килешүнең **4.4.2 пункты** нигезендә әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр буенча Алучыга аңлатмалар җибәрергә;

4.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты хокуклы:

4.2.1. әлеге Килешүнең шартларын үзгәртү турында Карар кабул итәргә, шул исәптән әлеге Килешүнең **4.4.1 пункты** нигезендә Алучы тарафыннан җибәрелгән мәгълүмат һәм тәкъдимнәр нигезендә дә.

4.2.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән яисә җирле үзидарә органыннан, дәүләт финанс контроле органыннан, Алучы тарафыннан Субсидия бирү кагыйдәләрендә һәм әлеге Килешүдә каралган тәртипне, максатларны һәм шартларны бозу факт(лар)ы турында мәгълүмат алынган очракта, шул исәптән әлеге Килешү нигезендә Алучы тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелгәндә, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәнче, субсидияләр бирүне туктатып торырга, Алучыга туктатып тору турында Карар кабул ителгәннән соң, 20 эш көненнән дә соңга калмыйча мәҗбүри хәбәр итеп;

4.2.3. алучыдан субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге килешүдә билгеләнгән субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә

соратып алырга:

4.3. Алучы түбәндәгеләрне үз өстенә ала:

4.3.1. әлеге Килешүнең 3.1.2 пунктында билгеләнгән документларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырырга;

4.3.4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты соратуы буенча әлеге Килешүнең **4.2.3 пункты** нигезендә субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны әлеге гарызнамә алынган көннән соң 10 эш көне эчендә җибәрергә;

4.3.5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетыннан әлеге Килешүнең 4.1.5 пункты нигезендә таләпләр алынган очракта:

4.3.5.1. күрсәтелгән таләптә билгеләнгән срокларда субсидияләр бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу факт(лар)ын бетерергә;

4.3.5.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле бюджетына күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Субсидияне кире кайтарырга:

4.3.6. әлеге Килешү нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итәргә;

4.4. Алучы хокуклы:

4.4.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр җибәрергә;

4.4.2. әлеге Килешүнең үтәлеше белән бәйле аңлатмаларны алу максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итәргә.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр, тиешле беркетмәләрне яки башка документларны рәсмиләштерү юлы белән, мөмкин булганча, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгәндә, Яклар арасындагы бәхәсләрне суд тәртибендә хәл итәләр.

6.2. Әлеге Килешү якларның һәркайсы исеменнән эш итәргә хокукы булган, ләкин әлеге килешүнең **2.1 пунктында** күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын элек җиткермәгән затлар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм әлеге Килешү буенча Яклар тарафыннан үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

6.3. Әлеге Килешүне үзгәртү, шул исәптән әлеге Килешүнең **4.2.1 пункты** нигезләмәләре нигезендә, Яклар килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге килешүгә Өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.4. Әлеге Килешүне өзү түбәндәге очракларда мөмкин:

6.4.1. Субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия

бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозулар:

6.5. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан кәгазь документ рәвешендә ике нөсхәдә, һәр Як өчен бер нөсхәдә төзелгән.

## VIII. Якларның түләү реквизитлары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | |
| Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т.юл. ст. пос., Кооператив ур., 5й<br>**ИНН/КПП** 1616014806/161601001<br>ЛБ 169030227 - мунИСП<br>**р/с** 03231643926220001100<br>**БИК** 019205400<br>**Банк** Бүлек – Россия Банкының Татарстан Республикасы МБ // Татарстан Республикасы буенча УФК Казан ш.<br>Кор.счет: 40102810445370000079<br>**ОГРН** 1061683000280<br>**ОКПО** 93078621<br>**ОКТМО** 92622440<br>**ОКВЭД** 84.11.31 | |

## IX. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | |
| ________________ | ____________________ |

3 нче кушымта

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» карарына

**2022 елның «__» ______нә гражданнар - Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга алты һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган субсидияләр алучылар**

**РЕЕСТРЫ**

| т/б | Гариза бирүченең Ф.И.А. | ИНН | Яшәү адресы, яшәү урыны буенча теркәлү | ШЯХта сыерлар саны, 2022 елның 1 гыйнварына баш | ШЯХта сыерлар саны, 2022 елның 1 июленә баш | Банк реквизитлары | Түләүгә сумма, сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары ______________________ (_______________)

(имза/ ФИА)